ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 октябрь 2025 ел № 8853

«2026-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2 Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 29 октябрендәге
8853 номерлы карарына
кушымта

«2026-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен
һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен
һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2026-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» 1991 елның 25 октябрендәге 1807-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге УП-312 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 сентябрендә 821 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүдәт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе |
| Программаны үтәүчеләр | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| Программаның максаты | Татар, рус һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче башка халыклар телләрен саклау, өйрәнү, үстерү өчен шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | 1. Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең тигез хокуклы яшәешенә ярдәм итү.<br>2. Россия Федерациясенең дәүләт телендә белем алуның бербөтен системасын үстерү, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениеләре мөмкинлекләре чикләрендә Россия |

<table>
<tr><td></td><td colspan="7">Федерациясе халыклары арасыннан укыту һәм тәрбия бирү телен сайлау.<br>3. Татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм итү.<br>4. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халык вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү<br>5. Дәүләт һәм Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче башка халыклар телләренең социаль статусын арттыру һәм аларны популярлаштыру.</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="6">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2026 ел</td><td>2027 ел</td><td>2028 ел</td><td>2029 ел</td><td>2030 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="7">2026 - 2030 еллар</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="7">1. Норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгару.<br>2. Татарстан Республикасы Яр Чаллы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару.<br>3. Россия Федерациясе дәүләт телендә белем алу, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениеләре мөмкинлекләре чикләрендә Россия Федерациясе халыклары арасыннан укыту һәм тәрбия бирү телен сайлау.<br>4. Муниципаль учреждение биналарында ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын урнаштыру.<br>5. Муниципаль учреждение биналары фасадларындагы язуларны, урам һәм юл күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү.<br>6. Хезмәт күрсәтү өлкәсенең муниципаль предприятиеләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белешмә мәгълүматлар булу.<br>7. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларга карата хөрмәт хисе формалаштыру.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруны контрольдә тотуны оештыру системасы</td><td colspan="7">Программаның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет гамәлгә ашыра</td></tr>
</table>

## 2 бүлек. Программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың эчтәлеге

Милли мәгариф һәм тәрбия, татар телен тормыш эшчәнлегенең барлык өлкәләрендә куллануны киңәйтү туган (татар) телне саклауда мөһим фактор булып тора. Яр Чаллы шәһәрендә тел өлкәсендә шәхеснең конституцион хокукларын тормышка ашыру өчен шартлар үтәлә, укучыларны туган телләрендә укыту һәм тәрбия бирү өчен тиешле шартлар тудырылган. Ике дәүләт теленең конституция статусына максатчан рәвештә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләнә.

Башкарма комитетның мәгариф идарәсе карамагында 129 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе бар. Шәһәрнең 129 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә татар милләтеннән булган 12 970 бала тәрбияләнә, бу мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендәге балаларның гомуми санынан 45,5% тәшкил итә.

Ике мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә - «Гөлназ» 49 нчы МБМББУ һәм «Көнбагышкай» 82 нче МБМББУда белем бирү процессы тулысынча татар телендә оештырылган. Аларда 382 бала тәрбияләнә.

Шәһәр балалар бакчаларында 1454 төркем эшли, шуларның 348 белем һәм тәрбия бирү татар телендә булган төркемнәр (23,93%).

Татар телендә укыту һәм тәрбия бирү төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр саны - 7 439, шуларның 96,09 % - татар милләтеннән булган балалар, 3,14 % - катнаш никахта туган балалар, 0,8% - башка милләтләр.

Татар телендә белем бирүче яңа комплектланган төркемнәрдә бары тик 31% бала гына туган телен югары дәрәҗәдә белә (сөйләмне аңлыйлар, бирелгән сорауларга җавап бирәләр, аралашуны башлап җибәрәләр).

Яр Чаллы шәһәренең 83 белем бирү оешмасында 62 дән артык милләт балалары, 73 002 укучы белем ала. Иң күп санлылары: татарлар - 33 887 (46,1%), руслар - 27 987 (38,6%), башка милләтләр - 11 128 (15,3%).

Шәһәрдә 11 татар мәктәбе эшли, шуларның 3 гимназия (2 нче, 29 нчы, 54нче), икесе лицей-интернат (79 нчы, 84 нче), фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган бер мәктәп (18 нче). Татар телендә белем бирү оешмаларының саны күп еллар дәвамында үзгәрешсез кала, аларда укучылар саны артуның уңай динамикасы күзәтелә.

2024-2025 уку елында белем бирү оешмаларында 182 сыйныфта, ата-аналар гаризасы нигезендә татар милләтеннән булган 4440 укучы фәннәрне туган (татар) телендә өйрәнә (узган уку елында сыйныфлар саны 154 иде).

Нәтиҗәдә, шәһәр буенча туган телдә белем бирү 13,1% тәшкил итә, узган ел белән чагыштырганда 1,9% ка үсеш күзәтелә.

Шулай ук шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында татар телендә тәрбия бирүче 391 сыйныф комплектланган, укучылар саны 8081 кеше (узган уку елында сыйныфлар саны 369 иде).

Шулай итеп, шәһәр мәктәпләрендә 12 521 укучы туган телдә укыту һәм тәрбия бирүче сыйныфларда белем ала, бу 36,95% тәшкил итә. Узган ел белән чагыштыргада 2,59 % үсеш күзәтелә.

Башкарма комитетның, педагогик җәмәгатьчелекнең милли үзаңны торгызу өчен шартлар тудыру буенча системалы эше милли мәгариф базасын саклап калырга, күп мәдәниятле мохит моделен үстерергә мөмкинлек бирә.

«Чишмә» халыклар дуслыгы йорты»нда туган телне яратучыларның 11 клуб берләшмәләре эшли. Бу клубларда мари, әрмән, азербайҗан, башкорт, таҗик, немец, чуаш, лезгин милләтеннән булган һәм керәшен балалары туган халкының милли мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрен, туган телләрен өйрәнәләр.

Телләрне үстерүгә мәгълүмати киңлек зур йогынты ясый. Соңгы вакытта телләрнең сүз байлыгы киму, орфография, пунктуация һәм стилистика хаталарның

артуы күзәтелә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында да. Яшьләр теле акланмаган чит ил алынмалары, жаргонизмнар, вульгаризмнар һәм компьютер лексикасы белән тулган. Иҗтимагый оешмаларның актив катнашында дәүләт, ведомство һәм муниципаль хакимиятнең барлык дәрәҗәләрендә телләрне саклау механизмын эшләү зарур.

Глобальләшү шартларында Россиядә дә, бөтен дөньяда да татарларның мәдәни ассимиляция процесслары көчәя, татар теле берсүзсез трансляторы булган милли үзенчәлекләр һәм гасырлар буе дәвам иткән гореф-гадәтләр югала. Туган телен белгән татарлар саны кимү тенденциясе саклана. Татар телен белү дәрәҗәсе түбәнәю белән беррәттән, татар телен куллану, шул исәптән халыкның көндәлек аралашуы шартларында да эштә, көн-күрештә кимүе күзәтелә. Бу процесслар татар телендә белем бирүче сыйныфлар санының кимүенә, һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында татар бүлекләре булмавына, туган татар телендә белем бирү системасының тулы көчкә эшләве өчен сәяси-хокукый һәм институциональ мөмкинлекләрнең югалуына китерә. Татар халкының туган телен һәм этник мәдәниятен югалту куркынычы татар телен, әдәбиятын һәм мәдәниятен саклау, үстерү һәм тарату проблемасының актуальлеген арттыра.

Әлеге Программа, проблеманың барлык өлкәләрен һәм аспектларын, күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген һәм Программаның телләрнең яшәргә сәләтле булуына йогынты ясый торган барлык төп факторларына йогынтысы нәтиҗәлелеген колачлауның бөтенлеген тәэмин итүгә корылган яңа төп принциплардан файдаланып, алдагы программаларны тормышка ашыру тәҗрибәсен анализлау нигезендә эшләнде.

## 3 бүлек. Программаның максаты һәм бурычлары

Программа Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп принциплары нигезендә эшләнде, алар телләрнең үсешен һәм гармонияле үзара хезмәттәшлеген, республикада яшәүче халыклар вәкилләренең милли, тел мәнфәгатьләренең тотрыклы балансын саклауны күздә тота.

Программаның максаты — татар, рус, һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче башка халыклар телләрен, шулай ук республикадан читтә татар телен саклау, өйрәнү һәм үстерү өчен шартлар тудыру.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны тормышка ашыруны күздә тота:

1) Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең тигез хокуклы яшәешенә ярдәм итү;

2) Россия Федерациясенең дәүләт телендә белем алуның бербөтен системасын үстерү, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениеләре мөмкинлекләре чикләрендә Россия Федерациясе халыклары арасыннан укыту һәм тәрбия бирү телен сайлау;

3) Татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм итү;

4) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халык вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү;

5) дәүләт һәм Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче башка халыклар телләренең социаль статусын арттыру һәм аларны популярлаштыру.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

| №<br>т/б | Этапның исеме | Тормышка ашыру чоры |
|---|---|---|
| 1. | Программаны тормышка ашыру | 2026-2030 еллар |
| 2. | Йомгак ясау | 2030 елның 4 кварталы |

## 5 бүлек. Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары

<table>
<tr><td rowspan="3">Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре</td><td colspan="6">Финанслау күләме (мең. сум.)</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td colspan="5">Шул исәптән еллар буенча</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>2027</td><td>2028</td><td>2029</td><td>2030</td></tr>
<tr><td>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
</table>

## 6 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләр

Программаның нәтиҗәлелеге чараларны билгеләнгән срокларда үтәү дәрәҗәсе буенча бәяләнә. Программаны тормышка ашыру түбәндәге нәтиҗәләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

1) норматив хокукый актларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә бастырып чыгаруны;

2) Татарстан Республикасы Яр Чаллы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып баруны;

3) Россия Федерациясе дәүләт телендә белем алу, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениеләре мөмкинлекләре чикләрендә Россия Федерациясе халыклары арасыннан укыту һәм тәрбия бирү телен сайлауны;

4) муниципаль учреждение биналарында ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын урнаштыруны;

5) муниципаль учреждение биналары фасадларындагы язуларны, урам һәм юл күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерүне.

6) хезмәт күрсәтү өлкәсенең муниципаль предприятиеләрендә Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә белешмә мәгълүматлар булуын;

7) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларга карата хөрмәт хисе формалаштыруны.

7 бүлек. Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

| № т/б | Индикатор исеме | Исәпләү формуласы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Эш кәгазьләрен алып баруда Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә башкарылган документлар өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N – эш кәгазьләрен алып баруда Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә башкарылган документлар саны;<br>$D$ – эш кәгазьләрен алып баруда документларның гомуми саны | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе |
| 2. | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N – Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чаралары саны;<br>$D$ – Яр Чаллы шәһәрендәге тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларының гомуми саны | Җирле үзидарә органнары һәм аларның ведмство буйсынуындагы оешмалар, муниципаль белем бирү учреждениеләре |
| 3. | Юл күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N – Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән юл күрсәткечләре саны;<br>$D$ – Яр Чаллы шәһәре юл күрсәткечләренең гомуми саны. | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br><br>N – Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерелгән урам күрсәткечләре саны;<br><br>*D* – Яр Чаллы шәһәре урам күрсәткечләренең гомуми саны. | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе |
| 5. | Гомуми белем бирү учреждениеяләрендә «Туган тел һәм әдәбияты» (татар) фәнен сайлауда катнашучылар өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br><br>N - «Туган тел һәм әдәбияты»н (татар) саулаучы укучылар саны;<br><br>D - татар милләтеннән булган укучыларның гомуми саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, «БАРС, Мәгариф» системасы (статистика хисабы) |
| 6. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларга туган татар телендә белем һәм тәрбия бирүне сайлауда катнашучылар өлеше, процент | $\frac{N}{D} * 100\%$<br><br>N - татар төркемнәрендәге балалар саны;<br><br>D - мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә татар милләтеннән булган балаларның гомуми саны | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, «БАРС, Мәгариф» системасы (статистика хисабы) |

8 бүлек. Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, чаралары һәм чаралар буенча финанслау

| № т/б | Чараларның исемнәре | Башкаручылар | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | | Чыганакны күрсәтеп финанслау күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| | | | | | | | | | Җирле бюджет | | | | |
| Максат: Татар, рус һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче башка халыклар телләрен саклау, өйрәнү, үстерү өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1 бурыч: Татарстан Республикасының дәүләт телләре буларак татар һәм рус телләренең тигез хокуклы яшәешенә ярдәм итү | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Мәдәни чараларны Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә оештыру һәм алып бару | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 50 | 50 | 50 | 52 | 52 | - | - | - | - | - |
| 2. | Эш кәгазьләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә алып бару | Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | Эш кәгазьләрен алып баруда Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә башкарылган документлар өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 3. | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү | Башкарма комитетның тармак идарәләре | Тышкы һәм эчке визуаль мәгълүмат чараларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Юл күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Юл күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 5. | Урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Урам күрсәткечләрен Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә рәсмиләштерү өлеше, процент | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 6. | Шәһәр чараларын Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә оештыру һәм алып бару | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе (алга таба - мәгариф идарәсе) | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | - | - | - | - | - |
| 7. | Россия Федерациясе дәүләт телендә белем алу, шулай ук муниципаль белем бирү учреждениеләре мөмкинлекләре чикләрендә Россия Федерациясе халыклары арасыннан укыту телен сайлау | Мәгариф идарәсе | Телне сайлауда катнашучылар өлеше, проценты | 68 | 68 | 68 | 69 | 69 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга Россия Федерациясе дәүләт телендә белем һәм тәрбия бирү, шулай ук муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре мөмкинлекләре чикләрендә Россия Федерациясе халыклары арасыннан укыту һәм тәрбия бирү телен сайлау | Мәгариф идарәсе | Телне сайлауда катнашучылар өлеше, проценты | 60 | 60 | 61 | 61 | 62 | - | - | - | - | - |
| 9. | «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» конкурсында катнашу | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, МББУ | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - | - | - |
| 10. | Рус теле көнен оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | 2000 | - | - | - | - | - |
| 11. | Г.Тукайга багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 6600 | 6990 | 7395 | 7745 | 8155 | - | - | - | - | - |
| 12. | Спортның милли төрләре буенча ярышлар һәм турнирлар уздыру | Башкарма комитетының физик культура һәм спорт идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 200 | 200 | 200 | 200 | 200 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 бурыч: Татар һәм рус телләрен өйрәнүнең һәм татар һәм рус телләрендә укытуның бербөтен системасын үстерү | | | | | | | | | | | | | |
| 13. | Шәһәр программаларын туган татар телендә оештыру | Мәгариф идарәсе | Татар телендә программалар саны, берәмлек | 5 | 5 | 5 | 5 | 5 | - | - | - | - | - |
| 14. | Мәктәп яшендәге балаларны укыту һәм тәрбия бирү буенча интернет ресурслар эшләү буенча конкурс оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, берәмлек | 64 | 64 | 64 | 64 | 64 | - | - | - | - | - |
| 15. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту һәм тәрбия бирү буенча интернет ресурслар эшләү буенча конкурс оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, берәмлек | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | - | - | - | - | - |
| 16. | Татар, рус теленнән олимпидалар оештыру һәм үткәрү (мәктәп, муниципаль турлары), республика турында һәм рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты буенча Халыкара олимпиадада катнашуны тәэмин итү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 40 | 40 | 40 | 40 | 40 | - | - | - | - | - |
| 17. | Педагогик укулар, республика фәнни-гамәли конференцияләренең | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль турларын оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | | |
| 18. | Туган тел укытучылары өчен «Туган тел» мастер-классы Бөтенроссия конкурсының муниципаль турын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 | - | - | - | - | - |
| 19. | Туган (татар, рус) телендә эш тәҗрибәсен тарату, чаралар, дәресләрнең иң яхшы эшләнмәләре җыентыгын бастыру | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | - | - | - | - | - |
| 20. | «Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү оешмаларында 1-4 сыйныфларда туган (татар) телендә укытуның иң яхшы практикасы» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | 15 | - | - | - | - | - |
| 21. | «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә туган (татар) телдә тәрбия бирүнең иң яхшы практикасы» муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 20 | 20 | 20 | 20 | 20 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 бурыч: Татар һәм рус телләрен саклау һәм үстерү процессларына фәнни һәм фәнни-методик ярдәм итү | | | | | | | | | | | | | | |
| 22. | Татар һәм рус теле укытучылары өчен укыту семинарлары оештыру һәм үткәрү, региональ киңәшмәләрдә, семинарларда катнашу | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 500 | 500 | 500 | 500 | 500 | - | - | - | - | - |
| 23. | Балаларга татар телен укыту буенча тәрбиячеләр өчен укыту семинарлары оештыру һәм үткәрү, регионалль киңәшмәләрдә, семинарларда катнашу | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | - | - | - | - | - |
| 4 бурыч: Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең телләрен саклау һәм үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| 24. | Яр Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмаларында халыкара Туган тел көнен оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 65 | 70 | 75 | 80 | 90 | - | - | - | - | - |
| 25. | Туган телне яратучылар клубы члтәрен саклау | Мәдәният идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 250 | 250 | 250 | 250 | 250 | - | - | - | - | - |
| 26. | «Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 60 | 60 | 60 | 60 | 60 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27. | «Мәдәниятләр диалогы» Идел буе халыклары фестивален оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 55 | 60 | 60 | 65 | 65 | - | - | - | - | - |
| 5 бурыч: Дәүләт һәм Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче башка халыклар телләренең социаль статусын күтәрү һәм популярлаштыру | | | | | | | | | | | | | | |
| 28. | «Татар малае» (1-4 сыйныф) муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, берәмлек | 115 | 115 | 120 | 120 | 120 | - | - | - | - | - |
| 29. | «Татар малае» (5-8 сыйныф) муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 115 | 115 | 120 | 120 | 120 | - | - | - | - | - |
| 30. | «Татар малае, татар кызы» (мәктәпкәчә яшьтәге балалар) муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 220 | 220 | 225 | 225 | 225 | - | - | - | - | - |
| 31. | «Татар кызы» (1-4 сыйныф) муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 65 | 68 | 70 | 70 | 70 | - | - | - | - | - |
| 32. | «Татар кызы» (5-8 сыйныф) муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 65 | 68 | 70 | 70 | 70 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 33. | «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 350 | 350 | 350 | 350 | 350 | - | - | - | - | - |
| 34. | Төрле халык телләрендә, туган телдә сәнгатьле укучылар конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 180 | 180 | 180 | 180 | 180 | - | - | - | - | - |
| 35. | «Бердәмлек» шәһәр программасын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 1015 | 1015 | 1020 | 1020 | 1020 | - | - | - | - | - |
| 36. | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары»муниципаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Мәгариф идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 315 | 320 | 325 | 325 | 325 | - | - | - | - | - |
| 37. | «ЖырлаОке» музыкаль конкурсы | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - | - | - | - |
| 38. | Заманча татар мәдәнияте фестивале (Open air креатив индустрия) | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 39. | Кунакханә «Дуспочмак» шәһәр конкурсы | Яшьләр белән эшләү идарәсе | Катнашучылар саны, кеше | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | - | - | - | - | - |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева